КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 31 май г.Казань № 507

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 841 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 841 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 11 декабрь, 1211 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып), беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2022 елга Татарстан Республикасында яшәү минимумы күләмен халыкның җан башына исәпләгәндә – 11 832 сум, эшкә яраклы халык өчен – 12 896 сум, пенсионерлар өчен – 10 175 сум, балалар өчен – 11 476 сум итеп расларга.».

2. Бу карар 2022 елның 1 июненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин